КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 апрель г.Казань № 361

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 август, 712 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 707 нче; 2015 ел, 27 август, 625 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1317 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 818 нче, 2021 ел, 13 декабрь, 1214 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эш тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлеше эшчәнлеге регламенты әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада китерелгән.»;

5 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының
электрон документлар әйләнеше
бердәм ведомствоара системасының
«Контроль» модуле эш тәртибенә
5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 апрель, 361 нче
карары редакциясендә)

«Контроль» модуленең «Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлеше эшчәнлеге регламенты

## I. Терминнар һәм билгеләмәләр

«Контроль» модуленең «Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлеше эшләү регламентында (алга таба – Регламент) аны куллану максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

ЭДӘБВС – Татарстан Республикасында электрон документлар алмашу, шулай ук электрон оештыру-күрсәтмә документларын булдыру, алардан файдалану, тапшыру һәм саклау өчен хезмәт итә торган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы;

«Контроль» модуле - Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләрен күзәтүне тәэмин итүче һәм «шәхси кабинет» һәм «мобиль кушымта» ярдәмче модульләреннән торучы ЭДӘБВС модуле;

«Контроль» модуленең «Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлеше – Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең максатчан мәгънәләренә ирешү барышы турында мәгълүматны җыю, мониторинглау һәм тикшереп тору механизмы (алга таба – федераль күрсәткечләр);

заявка – кулланучыларга «Контроль» модуленә керү мөмкинлеген бирү яисә туктату максатында ЭДӘБВС аша җибәрелә торган гарызнамә;

күрсәткеч – «Контроль» модуленең сан рәвешендә белдерелгән билгеле бер юнәлеше кысаларында объектның, процессның , продукт булдыру нәтиҗәсенең, хезмәт күрсәтүнең, эшнең гомумиләштерелгән характеристикасы;

шәхси кабинет – «Контроль» модуленең күрсәткечләр кертү, шулай ук аларны җаваплы башкаручылар тарафыннан мониторинглау һәм контрольдә тоту һәм координатор тарафыннан кертелгән күрсәткечләрне килештерү өчен билгеләнгән «Контроль» ярдәмче модуле;

мобиль кушымта – «Контроль» модуле координаторы тарафыннан кертелгән күрсәткечләрне килештерү өчен, шулай ук «Контроль» модуленең юнәлешләрен «Контроль» модулен юнәлешләре җитәкчеләре һәм башка кызыксынган затлар тарафыннан мониторинглау һәм контрольдә тоту өчен билгеләнгән мобиль җайланмалар өчен кушымта рәвешендәге «Контроль» модуле ярдәмче модуле;

оператор – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

администратор – «Контроль» модуленең техник һәм инфокоммуникация комплексының өзлексез эшләвен тәэмин итү, «Контроль» модулендә белешмәләр һәм реестрларны тулыландыру һәм актуальләштерү өчен оператор тарафыннан вәкаләтләр бирелгән оешма;

«Контроль» модуле юнәлешләре җитәкчесе – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры;

«Контроль» модуле юнәлеше координаторы – Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары;

җаваплы башкаручы – аңа керү мөмкинлеге бирелгән «Контроль» модуле юнәлеше буенча күрсәткечләрне кертүгә һәм (яисә) анализлауга җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы хезмәткәре;

кулланучы – «Контроль» модуле юнәлеше җитәкчесе, «Контроль» модуле координаторы, җаваплы башкаручы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы җитәкчесе, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында»Контроль» модуленең әлеге юнәлешен карауга керү мөмкинлеге булган башка кызыксынган зат;

Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү – Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан ел саен төзелә торган федераль күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләренә ирешү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе субъектлары рейтингы;

муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән федераль күрсәткеч – аның нигезендә муниципаль дәрәҗәдә федераль күрсәткечкә ирешү мониторингы үткәрелә торган федераль күрсәткеч, ярдәмче күрсәткеч яисә алмаштыручы күрсәткеч.

II. «Контроль» модуленең «Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча гамәлләр тәртибе

| Т/с | Юнәлешнең эшчәнлеген тәэмин итү гамәлләре | Мәгълүмати процессның субъекты | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Кулланучыларга файдалану мөмкинлеген бирү/туктату | | | |
| 1.1. | Заявканы ЭДӘБВС аша әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча кулланучыларга «Контроль» модуле юнәлешенең җитәкчесе адресына файдалану мөмкинлеген бирү (туктату) өчен җибәрү. | «Контроль» модуленең «Югары вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү» юнәлешен гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре (килешү буенча) | кирәк булган саен |
| 1.2. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эш тәртибенең (алга таба - Тәртип) IV бүлеге нигезендә кулланучыларга файдалану мөмкинлеген бирү (туктату). | «Контроль» модуле юнәлешенең операторы, администраторы, җитәкчесе | заявка кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә файдалану мөмкинлеге бирү (заявка кергән көннән алып өч эш көне эчендә керү мөмкинлеге туктатылу) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2. Шәхси кабинет ярдәмендә федераль күрсәткечләрнең һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләрен кертү | | | |
| 2.1. | Федераль күрсәткечләр һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләр буенча план чорына максатчан мәгънәләр (еллык, квартал) кертү | администратор (техник мөмкинлек булганда - әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә җаваплы башкаручылар) | хисап елның 20 мартына кадәр |
| 2.2. | Тәртипнең VI бүлеге нигезендә җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән белешмәләрне килештерү | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы (техник мөмкинлек булганда) | хисап елның 25 мартына кадәр |
| 3. Шәхси кабинет ярдәмендә федераль күрсәткечләрнең һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләренә үзгәрешләр кертү | | | |
| 3.1. | Әлеге Регламентның II бүлегенең 2 пункты нигезендә кертелгән мәгълүматка үзгәрешләр кертү | җаваплы башкаручы | максатчан мәгънәләрне билгели торган федераль норматив документларга яисә үзгәрешләрне раслый торган башка документларга үзгәрешләр кертелгән көннән алып җиде эш көне дәвамында |
| 3.2. | Тәртипнең VI бүлеге нигезендә җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән үзгәрешләрне килештерү | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы (техник мөмкинлек булганда) | килештерүгә мәгълүмат кергән көннән алып өч эш көне эчендә |
| 4. Федераль күрсәткечләрнең һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләренә ирешүнең факттагы дәрәҗәсе турында мәгълүмат кертү | | | |
| 4.1. | Узган елда федераль күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасы буенча факттагы күрсәткечләрне кертү | җаваплы башкаручы | Статистик эшләрнең федераль планы нигезендә Федераль дәүләт статистикасы хезмәте һәм рәсми статистик исәпкә алуның башка субъектлары тарафыннан статистик мәгъ- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | лүмат формалашканнан соң җиде эш көне дәвамында |
| 4.2. | Әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә федераль күрсәткечләр һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозиция-ләнгән күрсәткечләр буенча квартал саен фактик мәгънәләрен кертү | җаваплы башкаручы | квартал саен, хисап чорыннан соң 20 нче көнгә |
| 4.3. | Тәртипнең VII бүлегенең 7.3 пункты нигезендә федераль күрсәткечләрнең һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпо-зицияләнгән күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләренә ирешмәү сәбәпләре турында мәгълүмат кертү | җаваплы башкаручы | квартал саен, хисап чорыннан соң 20 нче көнгә, фактик мәгънәләрен кертү вакытында |
| 4.4. | Тәртипнең VI бүлеге нигезендә җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән федераль күрсәткечләрнең һәм муни-ципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрнең максатчан мәгънәлә-ренә ирешүнең факттагы дәрәҗәсе турында мәгълүматны килештерү | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы | квартал саен, хисап аеннан соң килүче айның 25 көненнән дә соңга калмыйча |
| 5. Хисап чорына элек кертелгән күрсәткечләргә үзгәрешләр кертү | | | |
| 5.1. | Федераль күрсәткечләр һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәт-кечләр буенча кертелгән барлык мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне гамәлгә ашыру, шулай ук ЭДӘБВС аша яисә электрон почтаның хезмәт адресларын файда-ланып, җаваплы башкаручыга искәр-мәләр һәм шәрехләр җибәрү | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы | хисап аеннан соң килүче 23 нче көннән дә соңга калмыйча |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5.2. | ЭДӘБВС аша «Контроль» модуле юнәлеше координаторына җибәреләторган сорауны федераль күрсәткечләр һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләр буенча элек кертелгән күрсәткечләргә үзгәрешләр кертүгә формалаштыру | җаваплы башкаручы | кирәк булган саен (сорату буенча) |
| 5.3. | Аларны тәгаенләү у максатларында элегрәк кертелгән күрсәткечләрдән файдалана алу мөмкинлеген ачуга җаваплы башкаручының килештерелгән заявкасын координатор тарафыннан администратор адресына җибәрүне | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы | җаваплы башкаручыдан заявка кергән көннән алып бер эш көне дәвамында |
| 5.4. | Алда кертелгән мәгълүматларны тәгаенләү өчен җаваплы башкаручыга керү мөмкинлеге бирү | администратор | «Контроль» модуле юнәлеше координаторыннан заявка кергән көннән соң өч эш көне эчендә |
| 5.5. | Элек кертелгән күрсәткечләргә үзгәрешләр кертү | җаваплы башкаручы | элек кертелгән мәгълүматларны тәгаенләү өчен керү мөмкинлеге ачылган көннән алып бер эш көне дәвамында |
| 5.6. | Тәртипнең VI бүлеге нигезендә җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән үзгәрешләрне килештерү | «Контроль» модуле юнәлешенең координаторы | килештерүгә мәгълүмат кергән көннән алып өч эш көне эчендә |
| 6. Федераль күрсәткечләрнең һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрнең казанышларын мониторинглау һәм анализлау | | | |
| 6.1. | Әлеге Регламентның II бүлегенең 4, 5 пунктлары нигезендә кертелгән һәм «Контроль» модуле юнәлешенең | оператор, администратор | квартал саен, хисап аеннан соң килүче айның 26 көненнән дә соңга калмыйча |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | координаторы белән килештерелгән мәгълүматны шәхси кабинетта һәм мобиль кушымтада автоматлаштырылган бастырып чыгару | | |
| 6.2. | Кертелгән мәгълүматларны анализлау нигезендә федераль күрсәткечләргә һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләргә ирешү мониторингы.<br>Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җибәрү өчен федераль күрсәткечләрнең максатчан мәгънәләренә ирешү нәтиҗәләре турында мәгълүмат-аналитик материаллар әзерләү сорату буенча) | «Контроль» модуле юнәлеше җитәкчесе,<br>«Контроль» модуле юнәлеше координаторы | соратуда күрсәтелгән сроклар нигезендә |